**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланны авыл җирлеге Шуганка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

13 ноябрь 2025 ел № 90

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Сез, 2025 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге Шуганка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 ( бер мең) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

**1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

- кышкы чорда авылындагы юлларны карап тоту, Ленин, Үзәк, Яшьләр, Совхоз урамнарын, зиратка юлны кардан чистарту шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Ленин, Үзәк, Яшьләр, Совхоз урамнарын, зират юлын җәйге чорда карап тоту өчен шартнамә буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Ленин, Үзәк, Яшьләр, Совхоз урамнар юлларын грейдерлау шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

**2) традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, ремонтлау:**

- зираттан каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау;
- зираттагы олы яшьтәге агачларны кисү;
- зиратның коймасын буяу;

**3) янгын куркынычсызлыгының беренче чараларын тәэмин итү:**

- янгынга каршы күрсәткечләрен сатып алу;
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру

**4) урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:**

- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү;
- урам яктырткычлары сатып алу;
- фонарь баганаларын сатып алу һәм урнаштыру;

**5) торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- үлән чабу;
- халыкның массакүләм ял итү мәйданчыкларын ремонтлау;

- үлән чаптыру өчен техника сатып алу;
- Сабантуй паркы өчен будка сатып алу һәм урнаштыру;
-Шуганка авылы территориясендә олы яшьтәге агачларны кисү һәм чистарту;

**6) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;
- суның сыйфатын анализлауны үткәрү;
-Санитар сак зонасы (ЗСО) проектын эшләү.

**7) Һәйкәлләрне ( Россәй Федераөиясе халыкларның мәдәни мирас обүектлары ( тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**
- Бөек Ватан сугышы истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау;

**8) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын ( чишмәләрне) төзекләндеру:**
- чишмәләрне киртәләү һәм ремонтлау өчен материал сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 287 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 158 ¸ бу 55 **%** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 152 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 6 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлегенең Шуганка торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге Шуганка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга җибәрергә:

**1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**
- кышкы чорда авылындагы юлларны карап тоту, Ленин, Үзәк, Яшьләр, Совхоз урамнарын, зиратка юлны кардан чистарту шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Ленин, Үзәк, Яшьләр, Совхоз урамнарын, зират юлын җәйге чорда карап тоту өчен шартнамә буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Ленин, Үзәк, Яшьләр, Совхоз урамнарынын юлын грейдерлау шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

**2) традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, ремонтлау:**

- зираттан каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау;
- зираттагы олы яшьтәге агачларны кисү;
- зиратның коймасын буяу;

**3) янгын куркынычсызлыгының беренче чараларын тәэмин итү:**

- янгынга каршы күрсәткечләр сатып алу;
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру

**4) урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләр һәм аларның астындагы мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр бәйләнешләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен багышланган башка җиһазларны ремонтлау:**

- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү;
- урам яктырткычлары сатып алу;
- фонарь баганаларын сатып алу һәм урнаштыру;

**5) торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- үлән чабу;
- халыкның массакүләм ял итү мәйданчыкларын ремонтлау;
- үлән чаптыру өчен техника сатып алу;
- Сабантуй паркы өчен будка сатып алу һәм урнаштыру;
- Шуганка авылы территориясендә олы яшьтәге агачларны кисү һәм чистарту;

**6) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;
- суның сыйфатын анализлауны үткәрү.

**7) һәйкәлләрне ( Россәй Федераөиясе халыкларның мәдәни мирас обүектлары ( тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**

- Бөек Ватан сугышы истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау;

**8) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын ( чишмәләрне) төзекләндерү:**

- чишмәләрне киртәләү һәм ремонтлау өчен материал сатып алу;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлегенең Шуганка торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://muslumovo.tatarstan.ru веб-адресында Мөслим муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Баланны авыл**
**җирлеге башлыгы** **Д.М.Гизетдинов**